ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 14.12.2016 г. Казань № 5-54/тэ

«2016-2018нче елларга «Осиново җылылык белән тәэмин итүче компаниясе» җаваплыгы чикләнгән җәмгыять тарафыннан кулланучыларга җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә) тарифларны билгеләү турында» 2016 елның 18 октябрендәге 5-11/тэ санлы Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты карары белән билгеләнгән «Осиново җылылык белән тәэмин итүче компаниясе» җаваплыгы чикләнгән җәмгыять тарафыннан кулланучыларга җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә) озак сроклы тарифларны 2017 елга үзгәртү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190 - ФЗ санлы Федераль законга, «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләр хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынучы бәяләрне (тарифларны) исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 2013 елның 13 июнендәге 760-э санлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп һәм 2017-2018 елларга «Осиново җылылык белән тәэмин итүче компаниясе» җаваплыгы чикләнгән җәмгыять тарафыннан кулланучыларга җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә) озак сроклы тарифларны төзәтү максатыннан, 2017-2018 елларга җайга салынулы оешмаларның планлы кирәкле тулай табышын ачыклап, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. “2016-2018нче елларга «Осиново җылылык белән тәэмин итүче компаниясе» җаваплыгы чикләнгән җәмгыять тарафыннан кулланучыларга

җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә) тарифларны билгеләү турында” 2016 елның 18 октябрендәге 5-11/тэ санлы Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты 1нче карарына үзгәрешләрне кертергә әлеге карар кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итергә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча Дәүләт
комитетының 14.12.2016 № 5-54/тэ
карарына кушымта
«Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча Дәүләт
комитетының 18.10.2016 № 5-11/тэ
карарына 1 кушымта

2016 – 2018 елларга календарьга бүлеп «Осиново җылылык белән тәэмин итүче компаниясе» җаваплыгы чикләнгән җәмгыять тарафыннан кулланучыларга җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә) тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлек, җайга салу-чы оешма исеме, тариф төре | Ел | Су | Басым астында алынган пар | | | | Әче һәм редукция-ләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 дән 2,5 кг/см$^{2}$- га ка-дәр | 2,5 дән 7,0 кг/см$^{2}$ га кадәр | 7,0 дән 13,0 кг/см$^{2}$ га кадәр | 13,0 кг/см$^{2}$ дан артыг-рак | |
| | Яшел үзән муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «Осиново җылылык белән тәэмин итүче компаниясе» җаваплыгы чикләнгән җәмгыять | | | | | | | |
| 1.1 | Кулланучылар өчен, тоташтыру схемасы буенча тарифларга дифференциация ясалмаган очракта | | | | | | | |
| | Бер ставкалы, сум./Гкал | карар үз көченә кергән көннән алып 31.12.2016 кадәр | 945,17 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2017 алып 30.06.2017 кадәр | 945,17 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2017 алып 31.12.2017 кадәр | 982,98 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2018 алып 30.06.2018 кадәр | 982,98 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2018 алып 31.12.2018 кадәр | 1022,20 | - | - | - | - | - |
| 1.2 | Халык (тарифлар НДСны исәпкә алып бирелгән)* | | | | | | | |
| | Бер ставкалы, сум./Гкал | карар үз көченә кергән көннән алып 31.12.2016 кадәр | 1115,30 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2017 алып 30.06.2017 кадәр | 1115,30 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2017 алып 31.12.2017 кадәр | 1159,92 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2018 алып 30.06.2018 кадәр | 1159,92 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2018 алып 31.12.2018 кадәр | 1206,20 | - | - | - | - | -» |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 маддәсе 6 пунктын гамәлгә ашыру максатыннан чыгып бүлеп бирелә

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының карарларының алыну
оештыру, тикшерү һәм алып бару бүлеге